Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

2022 елның 25 феврале №18/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге Советының «Чистай муниципаль районы «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 37/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2013 елның 25 июлендәге 37/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «якындагы территория» төшенчәсен төшереп калдырырга;

141.12 пунктының икенче абзацында "терлекчелек продуктлары" сүзләрен "терлекчелек продукциясе" сүзләренә алмаштырырга;

141.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«141.3. Төнлә урамда йөргән вакытта хайваннар хуҗалары урамнарда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү өчен чаралар күрергә тиеш.»;

144 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«144. Җирләү урыннарын карап тотуга карата таләпләр:

- зират территориясендә чүп-чар контейнерлары һәм чүп савытлары чистартылырга тиеш;

- агач утыртмаларының авария хәлендә булуы да рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга), шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

Татар Баганалысы авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Җәббаров